ГЛАВА ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

03.11.2020　　　　с. Печищи　　　　№ 4

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге
Печищи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020нче елның 23нче ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Печищи авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020нче елның 24нче ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Печищи авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2020нче елның 25нче ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Печищи авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2020нче елның 26нчы ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Печищи авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. 2020нче елның 27нче ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Печищи авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.
6. 2020нче елның 28нче ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Печищи авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын билгеләргә.
7. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Печищи авылының 1нче Май урамы, Кызыл Яр урамында яшәүчеләр

2 этап: Печищи авылының Декабристлар урамы, Грузин урамында яшәүчеләр
3 этап: Печищи авылының Красная Поляна урамында яшәүчеләр
4 этап: Печищи авылының Киров урамында яшәүчеләр
5 этап: Печищи авылының Калинин, Заречье, Искра урамнарында яшәүчеләр
6 этап: Печищи авылының Яңа урам, Яшьләр урамы, Исаев урамы, Лобачевский урамы, Дуслык урамы, Груздев урамы, Суворов урамы, Гагарин урамы, Гастелло урамы, М. Җәлил урамы, Зорге урамы, Кутузов урамы, Маяковский урамы, Курчатов урамы, Гудованцев урамнарында яшәүчеләр

8. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Печищи авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза булырсызмы:

- Печищи авылының поселок эчендәге юлларны ремонтлау өчен асфальт валчык сатып алу һәм тигезләү өчен махсус техниканы арендалау.

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Халык җыеннарын үткәрергә:

1 этап: Печищи авылының 1 Май урамы буенча 24нче йорт янында
2 этап: Печищи авылының Декабристлар урамы, 49 нчы йорт янында
3 этап: Печищи авылының Кызыл Алан урамы буенча 23Б номерлы йорт янында (кибет бинасы)
4 этап: Печищи авылының Киров урамы буенча 62нче йорт янында (Авыл мәдәният йорты бинасы)
5 этап: Печищи авылының Калинин урамы буенча 5нче номерлы йорт янында (мельзавод бинасы)
6 этап: Печищи авылының Яңа урамы буенча 20нче номерлы йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы Л. В. Яковлев